| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>БОЛЬШЕКАЙБИЦКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>КАЙБИЦКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН<br>РЕСПУБЛИКАСЫ<br>КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОНЫ<br>ОЛЫ КАЙБЫЧ АВЫЛ<br>ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

2019 елның 31 нче октябре Олы Кайбыч авылы № 24

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Олы Кайбыч авыл җирлеге Советының 2014 елның 19 нчы ноябрендәге 28 нче номерлы «Физик затлар мөлкәтенә салым турында»гы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Салым кодексының 32 нче бүлеге һәм Россия Федерациясенең аерым закон актлары нигезендә Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Олы Кайбыч авыл җирлеге Советы КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Олы Кайбыч авыл җирлеге Советының 2014 елның 19 нчы ноябрендәге 28 нче номерлы «Физик затлар мөлкәтенә салым турында»гы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2 нче пунктның 1 нче пунктчасының 2 нче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«гаражлар һәм машина урыннары, шул исәптән әлеге карарның 4 бүлегендә күрсәтелгән салым салу объектларында урнашкан урыннар;»;

1.2. 2 нче пунктның 2 нче пунктчасының 2 нче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«фатирлар, фатирлар өлешләре;»;

1.3. 2 нче пунктның 3 нче пунктчасының 2 нче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«торак йортлар, торак йортлар өлешләре;»;

1.4. Карарга түбәндәге редакциядә бәян итеп, 2.1 пунктын өстәргә.

«2.1. Физик затлар мөлкәтенә салым түләүдән түбәндәгеләрне азат итәргә:

2.1.1.18 яшькә кадәрге биш һәм аннан да күбрәк баласы булган гражданнарны;

2.1.2. Әлеге пунктның 2.1.1 пунктчасында күрсәтелгән гражданнарның балаларын».».

2. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Олы Кайбыч авыл җирлеге Советының 2018 елның 17 нче декабрендәге 25 нче номерлы «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Олы Кайбыч авыл җирлеге Советының 2014 елның 19 нчы ноябрендәге 28 нче номерлы «Физик затлар

мөлкәтенә салым турында»гы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында»гы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карар 2020 елның 1 гыйнварыннан, ләкин рәсми басылып чыккан көненнән бер айдан да иртәрәк булмаган вакытта үз көченә керә.

4. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http//pravo.tatarstan.ru Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында һәм Олы Кайбыч авыл җирлеге мәгълүматый стендларында бастырырга һәм Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Олы Кайбыч авыл җирлеге «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Совет Рәисе,
Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районы
Олы Кайбыч авыл җирлеге Башлыгы А.И. Рәхмәтуллин